СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2020 ел Баулы шәһәре № 25

Баулы муниципаль районының
балигъ булмаганнар эшләре һәм
аларның хокукларын яклау
комиссиясе турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 19 ноябрендәге 75 номерлы ТРЗ Татарстан Республикасы Законының, 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законының, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарын һәм учреждениеләрен координацияләү максатыннан Баулы муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Баулы муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия төзергә.

2. Кушымта нигезендә, Баулы муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составын расларга.

3. Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» 2018 елның 13 декабрендәге 189 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга (2019 елның 25 февралендәге 197 номерлы, 2019 елның 16

июлендәге 218 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 249 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 15 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Баулы
муниципаль районы Советының 2020
елның 15 декабрендәге 25 номерлы
карарына кушымта

Баулы муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе

СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Хөснуллина<br>Ильмира Илдус кызы | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| Сурова<br>Минзинә Рафаил кызы | «Яшьләр дөньясы» күп профильле яшьләр үзәге директоры, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сәхипова<br>Резеда Роберт кызы | Баулы муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау бүлеге начальнигы, комиссиянең җаваплы секретаре |

Комиссия әгъзаләре

| | |
|---|---|
| Аджалова<br>Светлана Мияссәр кызы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Баулы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Баһаутдинов<br>Камил Флер улы | Россия тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең Азнакай бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Барабанов<br>Игорь Анатольевич | Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең идарәсенең Баулы һәм Ютазы муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге начальнигы, эчке хезмәт подполковнигы (килешү буенча) |
| Гайсина<br>Лилия Хәкимҗан кызы | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ медицина психологы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гәрәйшин<br>Ринат Мөхәммәтҗан улы | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ табиб-наркологы (килешү буенча) |
| Ганиева<br>Дарина Зәйтүн кызы | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы |
| Иванова<br>Люция Харитоновна | «Үзәк» территориаль иҗтимагый үзидарәсе» җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Минәҗетдинова<br>Гүзәл Наис кызы | психолог (килешү буенча) |
| Сөләйманова<br>Лилия Заһит кызы | Баулы муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек начальнигы башлыгы |
| Солтанова<br>Рима Миргасим кызы | «Баулы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча) |
| Шәрәфиев<br>Илнур Шамил улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге полиция башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча), полиция капитаны (килешү буенча) |
| Юнысов<br>Рөстәм Сөләйман улы | Россия җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җинаять-үтәтү федераль казна инспекциясенең Бөгелмә муниципальара филиалының Баулы районы буенча начальнигы урынбасары (килешү буенча) |